**СОВЕТ ЧЕПЧУГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422736, Республика Татарстан, Высокогорский район с.Чепчуги ул.Советская, д.1

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЫПЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422736, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чыпчык авылы, Совет ур., 1

Тел./факс: +7(84365) 72-5-01, e-mail: Chep.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**19 октябрь 2020 ел** **№8**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, «Биектау муниципаль районының Чыпчык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлегенең норматив хокукый актларын хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, Биектау муниципаль район Чыпчык авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Үз көчләрен югалткан дип танырга:

Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 декабрендәге 26/1 нчы номерлы «Чыпчык авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Чыпчык авыл җирлеге җирле үзидарәсе рәсми сайтларында урнаштыру тәртибе һәм әлеге белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тапшыру турында Нигезләмәне раслау турында» карары;

Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 мартындагы 56 нче номерлы «Гражданнарның сәламәтлеген әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке тарту нәтиҗәләреннән саклау турында нигезләмәне раслау турында» карары;

Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 мартындагы 59/2 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Советының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советына тапшыру турында» карары;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының

хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы И.Р.Җиһаншин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
Чыпчык авыл җирлеге Советы
Совет Чепчуговского сельского поселения
ИНН 1616004928
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ВЫСОКОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН